# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы
Ютазы муниципал районы
Кәрәкәшле авыл җирлегенең Кәрәкәшле торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**14.12.2021 ел** **№ 1**

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»ГЫ 131-ФЗ санлы Федераль законның 25.1, 56 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе нигезендә, 2021 елның 14 декабрендә узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Кәрәкәшле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Кәрәкәшле торак пунктында зират территориясе коймасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү нигезендә эшләр өчен түләү);
- Кәрәкәшле торак пунктында авыл эчендәге юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту, килешү нигезендә эшләр өчен түләү);
- Кәрәкәшле торак пунктында су юлын ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алмаштыру, килешү нигезендә эшләр өчен түләү);

Кәрәкәшле торак пунктында санкцияләнмәгән чүплекләрне ликвидацияләү (килешү нигезендә эшләр өчен түләү);

- Кәрәкәшле торак пунктындагы Комсомол урамында җәяүлеләр басмасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу).»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 558 кеше кертелгән, тавыш бирүдә 286 кеше катнашты.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
халык җыенында катнашучы 286 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде;
«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены түбәндәге карар кабул итте:

1. Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлегенең Кәрәкәшле торак пунктында халык җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип исәпләргә.

2. "2022 елда Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Кәрәкәшле авыл җирлеге Кәрәкәшле торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, балигъ булган һәр кешедән 400 (дүрт йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- Кәрәкәшле торак пунктында зират территориясе коймасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү нигезендә эшләр өчен түләү);

- Кәрәкәшле торак пунктында авыл эчендәге юлларны карап тоту (юлларны кардан чистарту, килешү нигезендә эшләр өчен түләү);
- Кәрәкәшле торак пунктында су юлын ремонтлау (материаллар, җиһазлар сатып алу, өзеклекләрне бетерү, торбаларны алмаштыру, килешү нигезендә эшләр өчен түләү);

Кәрәкәшле торак пунктында санкцияләнмәгән чүплекләрне ликвидацияләү (килешү нигезендә эшләр өчен түләү);

- Кәрәкәшле торак пунктындагы Комсомол урамында җәяүлеләр басмасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу).» карарын кабул ителгән дип санарга.

3. Әлеге карарны Кәрәкәшле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http://jutaza.tatarstan.ru), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 5 көн эчендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Җыенда рәислек итүче,
Ютазы муниципаль районы
Кәрәкәшле авыл җирлеге башлыгы А.Г.Дәүләтгәрәев